| РАСПОРЯЖЕНИЕ<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>БОЕРЫГЫ |
|---|---|
| 31.01.2020 | № 69 |

**Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм террорчылыктан сакланырга тиешле дини оешмалар объектлары (территорияләре) исемлеген формалаштыру буенча вәкаләтле орган турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дини оешмалар объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланган булуына таләпләрне һәм дини оешмалар объектларының (территорияләренең) куркынычсызлык паспорты формасын раслау турында» 2019 елның 5 сентябрендәге 1165 номерлы карары нигезендә:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгын Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм террорчылыктан сакланырга тиешле дини оешмалар объектлары (территорияләре) исемлеген формалаштыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы дип билгеләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**